ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.09.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3092**

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү чыгару өчен 2024 елның дүртенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының нормативын билгеләү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 06 июлендәге 1219 номерлы карары белән расланган, «2020-2025 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен 2024 елның дүртенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының нормативын 86 065 (сиксән алты мең алтмыш биш) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин